**Чыганак:** Юзиев Н. Шигърият дөньясы: тәнкыйть мәкаләләре. - Казан, 1981

# ӘДИП ҺӘРВАКЫТ ЮЛДА

*(Шәйхи Маннур)*

Кешеләрнең кайгы-хәсрәтләрен,
Шатлыкларын килә җырласы.

*(Шәйхи Маннур)*

Һәр көн кич белән Ленин бакчасына җыелучы шахмат ветераннарына «шахмат җене кагылган» Шәйхи Маннурның кинәт югалуы баштагы шикелле хәзер сәер тоелмый: алар шагыйрьнең чираттагы сәфәргә юл тотуына, шулай еш кына озак вакытлар югалып торуына инде күнегеп беткәннәр. Ни әйтсәң дә шагыйрь шагыйрь инде! Аңа алдан уйланылган «комбинация»ләргә һичничек тә сыйдырып булмый торган җанлы тормыш кирәк, тормышның үз эченнән генә табып була торган кайнар йөрәкле кешеләр кирәк. Тормыш серләрен ачу аның өчен күп әһәмиятлерәк һәм кызыграк. Шуңа да ул тота да я үзенең туган Тулбай якларына кайтып әйләнә, я Әлмәт нефтьчеләренә юл тота, яисә Салават батыр иленә сәяхәт кыла, я Кара диңгез буйларына барып чыга.

Ерак юллар гизеп кайттым әле,
Ил киңлеген гиздем тагын бер;
Күз алдымда тора дөнья яме,
Рәхәтләнеп калды җаным бер,—

ди шагыйрь үзе ил гизү тәэсиреннән хозурланып.

Соңгы елларда Ш. Маннур сәяхәт маршрутын Муса Җәлил турында роман язу ниятеннән чыгып үзгәртеп корды. Романның герое бергә җырлашып үскән шагыйрь иптәше һәм фикердәш дусты булуы авторның эшеч шактый җиңеләйтә.

«Мусаны мин яхшы белә идем. Яшьлек елларыбызның шактый вакыты бер иҗат мәйданында узды, янәшә бүлмәләрдә һәм бергә эшләгән чакларыбыз да аз булмады. Шигъри бәхәсләр дә, фикердәшлек тә, бергәләп коллектив поэмалар язу да, икебез бер кызга кызыгып йөрүләр дә, бер бүлмә идәнендә рәттән тезелеп ятып йоклаулар да, бергә су коену, чаңгы шуу, күңел ачулар да булды... Шулай итеп, Муса белән шактый аралашып кичерелгән ундүрт ел эчендә миңа аның холкы-фигыле, гореф-гадәтләре, сөйләшү-фикер йөртү үзенчәлеге, ялкынлы табигате, мораль сафлыгы, һәйбәт коммунистлыгы, зур оештыру сәләте, кече күңеллелеге, кыскасы, аңа хас булган бөтен

сыйфатлары уч төбендәгедәй ачык иде»,— дип хәтерли автор үзе [1].

Бәлки икенче берәү Җәлил турындагы әсәрен шул материалларга таянып кына да язып чыккан булыр иде. Ләкин Ш. Маннурның характеры андый түгел шул. Ул тормышта үзенә, дусларына һәм язучы иптәшләренә таләпчән булган кебек, иҗатында да таләпчән. Бүлмәдән торып кына тормыш турында фәлсәфә сату аның өчен ят нәрсә. Ул үзе күргән, үзе белгән, үзе «тотып караган» нәрсәләр турында гына язарга күнеккән. Шуңа да аның поэзиясендә тормышчанлык көчле, Тайга яки Донбасс, Идел яки Днепр яклары укучыга аз билгеле булган конкрет бизәкләре, шул якларга гына хас кешеләре белән ачылалар.

Бу юлы да Ш. Маннур газета-журналларда Җәлил турында басылган хезмәтләр, истәлекләр белән генә канәгатьләнеп калмый. Аңа гына хас үҗәтлек белән, җентекләп, төпченеп Җәлилнең иҗатын, тормыш юлын өйрәнә.

Моабит циклы шигырьләрен кат-кат укып чыга, төрле шигырьләренең эчке мәгънәләрен ачарга омтыла, аларның кайчан, нинди урында, нинди рухи халәттә язылулары турында озак уйлана.

Җәлил эзләреннән Минзәләгә чыгып китә, андагы училище, Дусайкичү авылы, Ык буйлары белән таныша, Мусаны белгән кешеләр белән сөйләшә. Оренбургка, Мостафа авылына барып, Мусага бәйле барлык урыннарны карап йөри. Оренбургта шагыйрьнең сеңелләре Зәйнәп һәм Хәдичә Җәлиловалар белән очраша. Волхов фронтында Муса сугышкан җирләрдә була. Шагыйрьне фашист тоткынлыгында күргән-белгән кешеләрне хәтта «җәһәннәм тишегеннән» дә барып таба. Җәлил юлында сүтелеп калган җырларын һәм «серле йомгак»ның очын эзләп күп төрле киртәләрне җимереп үтә. Үзе олы яшьтә булса да, комсомол путевкасы юнәтеп, комсомол яшьләр белән Германиягә барып чыга. Анда ул Җәлил утырган Вустрау лагеренда була, Моабит, Тегель, Шпандау төрмәләрен карый, Җәлилне төрмәдә күреп-белгән рухани Юрытко белән очрашып сөйләшүгә ирешә.

Нәтиҗәдә роман өчен гаять бай материал туплана.

«Түл җыю» чоры тәмамлануга, 1959 елның гыйнварында каләм тотып эшкә утыра. Әмма яза башлагач романчылык тәҗрибәсе юклыгы мәгълүм була. Ш. Маннур романистларның тәҗрибәсен җентекләп өйрәнергә тотына. Рус һәм көнбатыш әдәбиятыннан йөзләгән роман белән таны-

---

[1] Ш. Маннур. Муса үзе сорады кебек... «Казан утлары», 1966, № 5.

шып чыга. Шулай яза торгач, биш ел дигәндә романның беренче варианты язылып бетә. Әмма соңгы ноктаны куйганчы тагын байтак вакытлар үтә. Ниһаять, Ш. Маннурның чираттагы ил гизүләренең һәм җитди өйрәнү-тикшеренүләренең йомгагы буларак «Муса» романы укучыларга барып ирешә.

Роман язу — зур сарай салу белән бер. Ул автордан зур тәҗрибә сорый. «Муса» романында да шушы тәҗрибәнең җитеп бетмәве сюжетта да, образ-характерларны сурәтләүдә дә әле үзен нык сиздерә. Аерым образларны гомумиләштерүдә бәхәсле урыннар да очрый. Шуңа карамастан, «Муса» татар әдәбияты өчен куанычлы күренеш булды. Укучылар да аны яратып каршы алдылар.

Шәйхи Маннур йөргән юллар картага төшерелсә, СССР картасы шактый куе сызыклар белән челтәрләнер иде. Шагыйрь күпне күрә, күпне ишетә. Күпне күрүнең бер сере шунда, ул үзе шул яңа тормыш төзергә олы юлга чыккан хезмәт кешеләре белән бер сафта көрәшче буларак атлый.

Шау-шу да мин, дан да эзләмәдем,  
Тик вөҗданым кушкан бу эшне  
Үтәдем мин — җаным җәлләмәдем,  
Үтәдем мин — ничек тиешле,—

дип язды шагыйрь үзе. Кузбасс, Донбасс шахталарында ул «күкрәкләргә газлы төтен йотып, төтенсез саф дөнья ясаучы»ларның берсе үзе була, бетонщик булып үзе чал Днепрны йөгәнләүдә катнаша, металлургия заводларында эшли. «Елмаюлы кояш турында» (1929) исемле шигырендә ул рабфак бетереп кайткан кызның «авылга кояш китерүе» турында язган шикелле, үзе дә Себер, тайга урманнары арасында адашкан авылларда «кояшны күрергә» өйрәтә. Юк, ул өйрәтеп кенә калмый, үзе дә халыктан күп нәрсәләрне өйрәнә. Һ. Такташ Маннур белән Донбасста очрашкач: «Шахтерлар средасы үзенең яхшы тәэсирен биргән»,— дип куен дәфтәренә юкка гына язмаган. Совет Армиясе сафларында туган илне фашистлардан саклап дошманның оясына кадәр булган озын авыр юл үтә. Шагыйрьнең үз сүзләре белән әйтсәк:

Ләкин гомер, бильярд шары кебек,  
Яшел сукно буйлап,  
Борттан-бортка уйнап,  
Тик тәгәрәп кенә узмаган.  
Гомер безнең: яшь ялкынын сибеп,  
Комсомолда янып,  
Якты очкын салып  
Күп күңелләр түрен нурлаган.

«Ил киңлеген» көрәшче булараҡ гизгән шагыйрьнең поэзиясе мөгаен шуңадыр да киң офыклы, нурлы, иркен сулышлы. Аңа көрәш рухы хас. Ул, Җәлил әйткәнчә, «җылылыгы, лиризмы, ялкынлы дәрте» белән үзенә тарта.

Ш. Маннурның лирик поэзиясе берничә буынның күңел түрләрен нурлап килә. Ул шигырьләр безнең әтиәниләрне рухландырган, тормышны сөяргә, аның матурлыгын күрергә, шул матурлык өчен көрәшергә өйрәткән. Безнең буын да Маннур шигырьләренең җылысын тоеп үсте.

Һәр буынның үз Маннуры бар. Егерменче еллар Маннуры ул — «Себер җыры», «Елмаюлы кояш турында», «Син юк инде», «Колчеданлы таулар өстендә». Ватан сугышы чоры һәм сугыштан соңгы еллар Маннуры ул — «Чәчәкләр һәм снарядлар», «Йөрәк типкән саен», «Язмыш мине...», «Кичке Идел», «Сагынган минутларда», «Матур кызга», «Язгы таңда», «Гомәр Хәйям белән сөйләшү».

Яшьләрнең һәм олыларның гына түгел, балаларның да үз Маннурлары бар. Бу — «Миләүшә китабы», «Авылга җыр килде», «Олаучы малай».

Ш. Маннурның тормышы гына түгел, поэзиясе дә хәрәкәттә, юлда булып, яңа тормыш матурлыгын ачарга чыккан шигърият булып күз алга баса.

Әдәбиятка ул Такташ, Туфаннар белән бер чордарак (беренче шигыре 1923 елны басыла) «йөрәкнең шашкын матурлыгы белән шашкын көйләр җырын» җырлап килеп керә. Үзе белән бергә яшьлек дәртен, яшьлеккә һәм шул чорга хас темалар алып килә.

Салкын Себер!
Гомерем синдә чәчәкләнде минем,
Синдә күңел
Кылын тибрәтте...
Сабыйлыгым алган салкын һава
Кайнар җырлар миңа өйрәтте!

дип язды ул «Миннән сәлам диген» (1927) исемле шигырьдә. «Туар заман уйлары» (1928) шигырендә ул үзенең максатын ачык итеп әйтә:

Кешеләрнең кайгы-хәсрәтләрен,
Шатлыкларын килә җырласы.
Сандугач та була белсәң иде,
Быргының да хаклы хуҗасы.

«Быргының хаклы хуҗасы булу», «сандугачтай җырчы булу», әлбәттә, яшь шагыйрьгә җиңел генә бирелми. Аңа тормышның байтак авырлыкларын җиңәргә, чорның каршылыкларын татырга туры килә. «Есенинчы, кулак

сандугачы» дигән исем белән, хәтта аны хаксызга ТАПП тан куалар:

Авыр миңа,
Кызыл сакчы көемә,
Кара тамга белән йөрүе.
Тик яшьлегем моңын әйткән өчен
Кемнәрнеңдер агу бирүе.

(«Сине сагындым», 1929)

Әмма шагыйрь көрәш быргысын — шигъри каләмен кулыннан ташламый, кешеләрнең шатлыкларын, кайгы-моңнарын җырлауны дәвам итә.

Һ. Такташ яшь шагыйрьнең беренче җыентыклары нигезендә үк «Маннур яхшы ук зур талант» дип бәя бирә. Бу сүзләрдән соң инде утыз елдан артык вакыт үтте. Ш. Маннур бөтен иҗат юлы белән үзен татар поэзиясенең зур таланты итеп танытты. Таланты тагы да чыныкты, яңа яклары белән ачылып китте.

Мин өзелеп сөям җирне,
Өзелеп сөям
Чәчәкне дә,
Кояш нурын да,—

дип язган иде шагыйрь 1929 елны.

Җирне, чәчәкне, кояшны өзелеп сөю, тормышка мәхәббәт аның бөтен иҗат юлы аша бүгенгәчә дәвам итә. Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат тәҗрибәсе ныгыган саен, акцент җиргә һәм чәчәкләргә генә түгел, Кешегә төшә бара. Хәзер шагыйрь җир, кояш, чәчәкләр янына иң әүвәле Кешене, аның йөрәген куя. Безгә шул йөрәкне шигырь «микроскобы» аша зурайтып күрсәтә. Шул сәбәпле без йөрәк кичергән шатлык тойгысын да, кайгы-моңын да ачык күрәбез.

Ш. Маннур кешенең күңел нечкәлекләрен, хис дулкыннарын ачкан матур лирик шигырьләр, җырлар иҗат итте. Шагыйрь заман рухы тәэсирендә буш яңгыравыклы, риторик шигырьләр дә язды. Тик алар тарих өчен генә калдылар. Шагыйрь шигъри юлда ул «багаж»ын һаман саен ташлый бара. Кешенең кыйммәтен һәм шәхеснең кабатланмас үзенчәлеген күрсәтергә, күңел түрләренә үтеп керергә булыша торган традицияләрне генә юлдашы итәргә омтыла.

«Шашкын» хисләр сабырлана, лирик шигырьләр дә азрак языла башлый. Ләкин шагыйрь олыгаюга карамастан, шигырьләре әчкерсез самимилекләрен, җылылыкларын югалтмый. Соңгы елларда шагыйрьдә уйланучы фи-

кер, акыл шигърияте өстенлек итә. Чәнечкеле, төртмә шигырьләр дә күренә башлады.

Шагыйрьнең үзенчәлекле фикерләве ул сурәтләгән тормыш материалында һәм лирик героенда гына түгел, шигъри бизәкләрендә дә, тасвир чараларында да, интонациясендә дә ачык гәүдәләнә.

Ә мин мохтаҗ җирнең шатлыгына,
Кояшлы шат җирне күрергә.
Бик яшисе килә җир өстендә
Кояштай шат булып гомергә.

(«Чәчелгән чәчәкләр», 1928)

яки:

Кояш кебек озын гомер телим
Үземә дә, дустым, сиңа да.
(«Эшче»нең ун еллыгына, 1928)
Ташка бәрер идем бу башымны,
Әгәр дөнья әрәм калмаса;
Әгәр кояш,
өмет нуры түгеп,
Сөю уты биреп янмаса!

(«ТАППтан куылгач», 1929)

кебек егерменче елларда язылган шигырь юлларында ук шагыйрьнең сурәтле фикерләвендә кояш образының әһәмиятле урын алуы, ул образда шагыйрьнең дөньяны үзенчә кабул итүе чагылды. Шагыйрь иҗатында шундый үзенчәлекле мәгънәви эчтәлек белән ачылган сурәтләрне байтак китерергә мөмкин булыр иде.

Тәфсыйллау, җентекләү — Ш. Маннурга хас алымнарның берсе. Аерым очракларда тәфсыйллау гаять отышлы яңгырый. Ә кайвакытта ул шагыйрьнең кимчелеге булып күренә, укучыны үзеннән биздергән күренеш булып та китә.

Поэзияне билгесезлеккә сәяхәт, диләр. Ш. Маннур үзенә хас шигъри юлларда безне еш кына билгесез тормыш эченә алып керә, кешеләрнең рухи дөньяларына сәяхәт иттерә, яңа кешеләр белән таныштыра.

Ш. Маннур үз гомерендә кешеләр белән аз очрашмады. Укучыларга да ул төрле җирләрне генә түгел, «гасырны иңнәрендә алып баручы» күп-күп кызыклы кешеләрне дә ачты. Менә кайчандыр мәзиндә батрак булып торган, ә хәзер Карабаш шахталарында «колчеданнан коймак пешерүче», илдәге социалистик ярыш дәрте белән янучы мөлаем егет Гарәфи («Колчеданлы таулар өстендә», 1929).

Менә гражданнар сугышы елларында Врангельне тар-мар итүдә арслан кебек сугышкан, ә хәзер чуен ташкыннары белән көрәшкә чыккан Сары Хисмәт («Чуен ташкыннар», 1930).

Поэмадан поэмага шагыйрьнең эпик osталыгы камилләшә бара, характерны индивидуаль үзенчәлекләре белән ачу тирәнәя. «Меңнән бер кичә», «Гайҗан бабай» поэмалары бу яктан шагыйрь иҗатында гына түгел, ә татар совет поэзиясе тарихында онытылмаслык эз калдырган әсәрләр булды. Бу поэмаларда элек «канатсыз коштай» яшәгән Гата, Миңнур картларның яңа тормыш тәэсирендә шәхес буларак үсүләрен, тормышның чын хуҗалары булып җитүләрен оста итеп сурәтләде:

Әкренләп калкам, һаман калкам
Ай шикелле — таулар астыннан.
Тик тагын да өскә менәсе иде,
Хәзер күңел шуңа ашкынган.

Бу — «Меңнән бер кичә» поэмасыннан Гата сүзләре. Ш. Маннурның тормышны кабул итүенең бер үзенчәлеге нәкъ менә шундый — кояшка омтылучы, «өскә менүче», менгән саен офыгы киңәюче геройларны сурәтләүдә. Миңнур картның беренче тапкыр самолетта очу шатлыгын шуңа да шагыйрь тирән мәгънәле күренеш итеп тасвирлый.

Искиткеч саф күңелле, инсафлы Дилбәрнең фронттагы батырлыгын, кулына байрак тоткан хәлдә тау башына менеп җиткәч һәлак булуын сурәтләве белән Ш. Маннур шундый әчкерсез, намуслы, саф табигатьле геройлар галереясен тагы да тулыландырды («Казан кызы», 1946). Үз вакытында тәнкыйть поэмадан бозыклык күренешләре эзләп маташты. Әмма ул чынында юк иде. Киресенчә, поэмада сугыш тәмугында да кешеләрнең әхлак сафлыгы, «чәчәк кебек керсезлеге», кешелек сыйфатларын саклап калулары, шул кешелек күркәмләгән күрсәтүләре җырлана.

«Җир-әнкәнең сылу кызы» повестендагы (1953—1956) образларның мораль пафосы исә сугыштан соңгы елларда Татарстан нефте өчен көрәш күренешләре белән бәйле. Биредә без Равил, Зәйнак, Гөлфая, Валя кебек үзенчәлекле язмышлы образлар белән очраштык. Кичәгечә яшәп буламы? — шушы сорауны повестьның геройлары үзләренә дә, кичәге көн белән яшәүче Туманаевларга да бирәләр, һәм иртәге көнне якынайту өчен армый-талмый көрәшәләр.

Ш. Маннур күп санлы поэмалары белән татар совет эпик поэзиясен үстерүгә зур өлеш кертте. Прозаикларча нечкәлек белән сурәтләнгән, рельефлы итеп коелган тормышчан образлары поэзиябезнең реалистик традицияләрен тагы да тирәнәйтте. Ш. Маннур геройларында, бер яктан, татар халкына хас күркәм сыйфатлар шактый калку гәүдәләнсә, икенче яктан, «чабаталы», «каеш кәпәчле» татар кешесенең бөкрәйгән аркасын турайтып Кояшка, өскә үрләве, яңа рухи матурлыклар белән баюы үзенчәлекле талант көче белән ачылды.

*1966*